ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

**_25.07.2024_________** **№__117-од_____**

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга югары белем бирү аерым мәгариф учреждениеләре студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы турында» 2022 елның 24 мартындагы 65-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга югары белем бирү аерым мәгариф учреждениеләре студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы турында» 2022 елның 24 мартындагы 65-од номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерык бирәм:»;

боерыкның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016-2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән расланган боерык белән расланган «Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты стипендиясен алуга югары белем бирү аерым мәгариф учреждениеләре студентлары арасында ел саен үткәрелә торган фәнни эшләр конкурсы турында» нигезләмәдә:

1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Конкурс турында мәгълүмат «Интернет» телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитеты, Дәүләт архивы рәсми сайтларына эшләр кабул ителә башлаганчы кимендә ун календарь көн кала урнаштырыла.»;

2.3 пунктта «Столбище авылы, Совет урамы, 277 нче йорт адресы буенча урнашкан Дәүләт архивының кабул итү бүлмәсенә үзләре алып барып тапшыра һәм/яки prm.gart@tatar.ru электрон почтасы аша» сүзләрен «Столбище авылы, Совет урамы, 277 нче йорт адресы буенча урнашкан Дәүләт архивына үзләре алып барып тапшыра яки почта элемтәсе аша һәм/яки Albina.Zigirova@tatar.ru электрон почтасы аша» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4 пункт өстәргә:

«2.4. Конкурс эшләрен кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- эшләрнең әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән конкурс эшләрен кабул итү срогы узгач тапшырылуы;

- конкурс эшенә әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында каралган документларның беркетелмәве (тулы күләмдә беркетелмәве);

- эшнең әлеге Нигезләмәнең 1.5, 4.1, 4.2., 4.3 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

- Конкурста катнашучының «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусы булуы.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункт өстәргә:

«2.5. Конкурс эшен кабул итүдән баш тарткан очракта, катнашучылар, кимчелекләрне бетергәннән соң, конкурс эшләрен кабул итү өчен билгеләнгән срокта эшне кабат бирергә хокуклы. Гаризаны кабат бирү бер мәртәбә рөхсәт ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.6 пункт өстәргә:

«2.6. Конкурска кертүдән баш тарту турындагы карар конкурс эше кергән көннән алып ике эш көне эчендә ТР Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителә.

Катнашучылар конкурска кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә бу хакта телефон элемтәсе аша, шулай ук әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматлар субъекты тарату өчен рөхсәт иткән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкта күрсәтелгән электрон почта адресы буенча хәбәр ителә».

3.2 пунктның беренче абзацында «Кимендә 9 кешедән гыйбарәт Комиссия составы Дәүләт комитеты тарафыннан ел саен төзелә һәм раслана.» сүзләрен «Кимендә 9 кешедән гыйбарәт Комиссия Дәүләт комитеты тарафыннан ел саен 15 апрельгә кадәр төзелә һәм раслана.»;

3.3 пунктының икенче абзацында «Читтән торып эшләү этабында Комиссия эшләрне үзенчәлекле булуга һәм «Антиплагиат» системасы буенча алынмалар булу-булмауга тикшерә.» сүзләрен «Читтән торып эшләү этабында Комиссия эшләрне үзенчәлекле булуга һәм «Антиплагиат» системасы буенча алынмалар булу-булмауга тикшерә (алынган текстлар текстның гомуми күләменнән 20% тан артык түгел).» сүзләренә алмаштырырга.»;

3.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурсның берничә катнашучысы бертигез баллар санын җыйса, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышларның гади күпчелеге белән Комиссия тарафыннан билгеләнә. Җыелган тавышлар саны тигез булганда, Комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.»;

3.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Боерык Дәүләт комитетының, Дәүләт архивының рәсми сайтларына расланган көннән соң өч календарь көн эчендә урнаштырыла.»

7.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган максатчан акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

түбәндәге эчтәлекле 7.3 пункт өстәргә:

«7.3. Конкурс уздыру чорында «Чит ил йогынтысында булган затларның эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган конкурста катнашучы диплом һәм акчалата бүләк белән бүләкләнми.»

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З.Габдрахманова